БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ РАЙОН
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
«25» 06 2025 ел

**КАРАР**
№ 185

Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының
кайбер карарларының үз көчен югалтуын тану турында

Балтач районы прокурорының 2025 елның 19 июнендәге 02-08-01-2025/Прдп269-25-20920011номерлы, 2025 елның 20 июнендәге 02-08-01-2025/Прдп283-25-20920011 номерлы протестын карап һәм «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты карар бирә:

1. Түбәндәгеләрне гамәлдән чыккан дип танырга:

- Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының 2022 елның 10 августындагы «Муниципаль һәм җирле әһәмияттәге автомобиль юллары буйлап авыр йөк ташучы транспорт чаралары китерә торган зыян күләмен билгеләү турында» 239 номерлы карарын.

- Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының 2017 елның 28 февралендәге «Татарстан Республикасы «Балтач муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтү чараларын гамәлгә ашыру турында» 104 номерлы карарын.

- Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының 2020 елның 25 маендагы «Балтач муниципаль районында аренда түләүләрен кичектереп тору өлешендә кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм чаралары турында» 185 номерлы карарын.

- Татарстан Республикасы Балтач районы башкарма комитетының 2020 елның 29 сентябрендәге «Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының «Балтач муниципаль районында аренда түләүләрен кичектереп тору өлешендә кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм чаралары турында» 2020 елның 25 маендагы 185 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 288 номерлы карарын.

- Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының 2010 елның 15 мартындагы «Балтач муниципаль районында гражданнар

оборонасы чараларын тәэмин итү һәм коткару хезмәтләре (гражданнар оборонасы хезмәтләре) булдыру турында» 117 номерлы карарын.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Балтач муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка житкерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Балтач район башкарма комитеты
житәкчесе А.Ф.Хәйретдинов